# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«22» июнь 2026 ел № 5

«Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында» 2023 елның 16 февралендәге 4 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Элемтә турында» Федераль законның 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясы 5 өлеше, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. «Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында» Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 16 февралендәге 4 номерлы карарына (Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.03.2025 № 4 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.7, 3.8 пунктларында «юл сервисы объектларын» сүзләреннән соң «элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2.4 пунктының 1 пунктчасында «юл сервисы объектларын» сүзләреннән соң «элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

1.3. 4 пунктының 2 пунктчасында «юл сервисы объектларына» сүзләреннән соң «элемтә линияләренә һәм элемтә корылмаларына» сүзләрен өстәргә;

1.4. 4 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4. «Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары һәм (яки) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү һәм үзгәртеп кору, алардан файдалану»;

1.5. 4.1 пунктында «салу, күчерү һәм үзгәртеп кору» сүзләрен «төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү һәм үзгәртеп кору», сүзләренә алыштырырга, «коммуникацияләре» сүзеннән соң «элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары» сүзләрен өстәргә;

1.6. 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары һәм (яки) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү һәм үзгәртеп кору, алардан файдалану инженерлык коммуникацияләре, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары хуҗалары яки алар хисабына инженер коммуникацияләре, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары хуҗалары тарафыннан автомобиль юлы хуҗасы белән төзелә торган шартнамә һәм төзелешкә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге Федераль закон нигезендә бирелә торган рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла (әгәр мондый рөхсәт Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге Федераль закон белән таләп ителсә). Әлеге шартнамә белән инженер коммуникацияләре, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары хуҗалары тарафыннан аларны төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда, шул исәптән салганда, күчергәндә, үзгәртеп корганда, эксплуатацияләгәндә үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләр һәм шартлар (алга таба әлеге статьяда - үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләр һәм шартлар) каралырга тиеш.»;

1.7. 4.3 пунктында «салу, күчерү һәм үзгәртеп кору» сүзләрен «төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү һәм үзгәртеп кору», сүзләренә алыштырырга, «коммуникацияләре» сүзеннән соң «элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары» сүзләрен өстәргә, «мондый» сүзен төшереп калдырырга;

1.8. 4.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары һәм (яки) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү һәм үзгәртеп кору, алардан файдалану инженерлык коммуникацияләре, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары хуҗалары яки алар хисабына автомобиль юлы хуҗасының язма ризалыгы булганда һәм төзелешкә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге Федераль закон нигезендә бирелә торган рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла (әгәр мондый рөхсәт Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге Федераль закон нигезендә таләп ителсә). Әлеге ризалык үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләрне һәм шартларны үз эченә алырга тиеш.»;

1.9. 4.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары һәм (яки) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлауганда, шул исәптән салганда, күчергәндә һәм үзгәртеп корганда төзелешкә рөхсәт аның бүлеп бирелгән полоса чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау,

шул исәптән салу, күчерү, үзгәртеп кору планлаштырылган автомобиль юлын төзүгә рөхсәт бирүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яки аның ведомствосындагы федераль дәүләт учреждениесе, Россия Федерациясе субъектының башкарма органы яки аның ведомствосындагы дәүләт учреждениесе, җирле үзидарә органы тарафыннан бирелә.»;

1.10. 4.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяның 2 һәм 3 өлешләрендә каралган ризалыктан, төзелешкә рөхсәттән башка (әгәр мондый рөхсәт Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге Федераль закон нигезендә таләп ителсә) яки үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләрне һәм шартларны бозып, аларны төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны, шул исәптән салуны, күчерүне, үзгәртеп коруны, эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы инженерлык коммуникацияләре, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары хуҗалары дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган һәм (яки) автомобиль юлы хуҗасы таләбе буенча инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны, шул исәптән салуны, күчерүне, үзгәртеп коруны, аларны эксплуатацияләүне туктатырга, законсыз корылган корылмаларны, башка объектларны сүтәргә һәм автомобиль юлын башлангыч хәленә китерергә бурычлы. Күрсәтелгән таләпләрне үтәүдән баш тарткан очракта, автомобиль юлы хуҗасы төзелгән, реконструкцияләнгән, капиталь ремонтланган, шул исәптән салынган, күчерелгән, үзгәртеп корылган инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын ликвидацияләү эшләрен әлеге эшләрне башкаруга киткән чыгымнарны алга таба Россия Федерациясе законнары нигезендә корылмаларны, башка объектларны законсыз төзүдә, реконструкцияләүдә, капиталь ремонтлауда, шул исәптән салуда, күчерүдә, үзгәртеп коруда гаепле затлар хисабына компенсацияләп башкара. Автомобиль юлы хуҗасының инженерлык коммуникацияләре, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары хуҗасы тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләрне һәм шартларны үтәүгә мониторингны гамәлгә ашыру тәртибе юл хуҗалыгы өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www. pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе — Р.Н. Абдульманова

Исполнительный комитет БУРДИНСКОГО сельского поселения
ИНН 1639032248